РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

«16» февраль 2026 ел — № 26

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында 2026 елны «Туризм елы» дип игълан итү турында

Район территориясен, инфраструктурасын үстерү, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының уникаль табигый, тарихи һәм мәдәни истәлекле урыннарын алга җибәрү, шулай ук районның туристлык потенциалын популярлаштыру максатларында Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында «Туризм елы» игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетына:

2.1. Проектны гамәлгә ашыру буенча эшче төркем төзергә һәм составын расларга.

2.2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесенә, «Мәдәният бүлеге» муниципаль учреждениесенә, «Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» муниципаль учреждениесенә «Юл картасы»н эшләүне һәм проектны гамәлгә ашыруны һәм «Туризм елы» проекты кысаларында чаралар үткәрүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе — Р.Т. Айбатов